**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 151-18 «26» июль 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2019 елның 20 августындагы 279-38 номерлы «Азнакай муниципаль районында муниципаль вазыйфалар биләүче затлар пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында нигезләмә» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата бүләкләү бирү тәртибе һәм күләме турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2019 елның 20 августындагы 279-38 номерлы «Азнакай муниципаль районында муниципаль вазыйфалар биләүче затлар пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе һәм күләмнәре турында нигезләмә» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата бүләкләү бирү тәртибе һәм күләме турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 2.1 бүлекнең 2.1 пунктындагы беренче абзацында «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясе, яки инвалидлык буенча пенсия билгеләү» сүзләрен «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча хезмәт пенсиясе» яки картлык буенча вакытыннан алда яисә инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләү)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин